№ 33. | I СЕНТЯБРЯ. | 1913.

ВЫХОДЯТЪ ЧЕТЫРЕ РАЗА ВЪ МѢСЯЦЪ.

# ИЗВѢСТІЯ ПО КАЗАНСКОЙ ЕПАРХІИ

РЕДАКЦІЯ КАЗАНЬ Духовн. Академія.

ИЗДАНІЕ ИМПЕРАТОРСКОЙ КАЗАНСКОЙ ДУХОВНОЙ АКАДЕМІИ.

**ПОДПИСНАЯ ЦѢНА:** съ приложеніемъ журнала „Православный Собесѣдникъ" епархіальнымъ подписчикамъ 8 р. Безъ прилож. 5 р.

## СОДЕРЖАНІЕ.

**Оффиціальный отдѣлъ.** Свободныя мѣста. 961. **Епархіальная хроника.** Архіерейскія служенія. 962. Поученія прот. Н. Воронцова, свящ. Н. Троицкаго и статья проф.-свящ. Ѳ. Успенскаго въ 1600-лѣтнюю годовщину изданія Миланскаго эдикта (14-го сентября 1913 г.) въ переводѣ на татарскій языкъ. 964. Объявленіе отъ Казанскаго Епархіальнаго женскаго училища. 984.

**Неоффиціальный отдѣлъ.** Слово предъ началомъ учебныхъ занятій. Проф.-свящ. *Ѳ. Успенскаго.* 985. Къ вопросу объ измѣненіи правилъ Образовательнаго Фонда духовенства Казанской епархіи. Прот. *Н. Владимірскаго.* 987. Изъ періодической печати. 996.

# ОФФИЦІАЛЬНЫЙ ОТДѢЛЪ.

## СВОБОДНЫЯ МѢСТА.

Священническія. При церквахъ: села Чипчигъ, Тетюшскаго уѣзда, прихожане—русскіе; села Ишакъ, Козмодемьянскаго уѣзда, прихожане—русскіе и чуваши; с. Русской Вылы, Ядринскаго уѣзда, прихожане—русскіе и чуваши; с. Юльялъ, Козмодемьянскаго уѣзда, прихожане—черемисы; Николаевскомъ, г. Чистополя, соборѣ, прихожане—русскіе; с. Никольскаго, Чистопольскаго уѣзда, прихожане—русскіе; Казанскомъ Богородицкомъ женскомъ монастырѣ; с. Юванова, Козмодемьянскаго уѣзда, прихожане—чуваши;

с. Ивановскаго, Казанскаго уѣзда, прихожане—русскіе и Пригорода Старошешминска, Чистопольскаго уѣзда, прихожане—русскіе.

Діаконскія. При церквахъ: села Мансурова, Лаишевскаго уѣзда, прихожане—русскіе и крещеные татары; с. Селенгушъ, Лаишевскаго уѣзда, прихожане—русскіе; с. Кузнечихи, Спасскаго уѣзда, прихожане—русскіе и с. Именева, Цивильскаго уѣзда, прихожане—чуваши.

Псаломщическія. При церквахъ: Воскресенской, города Казани и Макарьевской, города Казани.

---

# ЕПАРХІАЛЬНАЯ ХРОНИКА.

## Архіерейскія служенія.

*Августа 1-го.* Происхожденіе (выносъ) древъ Креста Господня.

Въ каѳедральномъ соборѣ Божественную Литургію и послѣ оной крестный ходъ на рѣку Казанку для водоосвященія совершилъ Преосвященнѣйшій Михаилъ Епископъ Чебоксарскій.

*Августа 6-го.* Преображеніе Господне.

Въ Спасо-Преображенскомъ монастырѣ Божественную Литургію и послѣ оной молебенъ совершилъ Высокопреосвященнѣйшій Іаковъ, Архіепископъ Казанскій и Свіяжскій, въ сослуженіи Преосвященнѣйшихъ Викаріевъ.

Предъ Литургіей изъ каѳедральнаго собора въ Спасскій монастырь былъ совершенъ крестный ходъ во главѣ съ Преосвященнѣйшимъ Михаиломъ.

Всенощное бдѣніе наканунѣ праздника въ Спасскомъ монастырѣ совершилъ Преосвященнѣйшій Анатолій.

*Августа 7-го. Среда.* Чтеніе Акаѳиста Св. Гурію въ каѳедральномъ соборѣ совершилъ Преосвященнѣйшій Михаилъ.

*Августа 15-го.* Успеніе Пресвятыя Богородицы.

Въ Зилантовскомъ Успенскомъ монастырѣ Божественную Литургію и послѣ оной молебенъ совершилъ Высокопреосвященнѣйшій Архіепископъ Іаковъ въ сослуженіи Преосвященнѣйшаго Анатолія.

— Въ Успенскомъ соборѣ Божественную Литургію и послѣ оной молебенъ совершилъ Преосвященнѣйшій Михаилъ.

Предъ Литургіей изъ каѳедральнаго собора въ Успенскій былъ совершенъ крестный ходъ.

Въ каѳедральномъ соборѣ наканунѣ праздника Всенощное бдѣніе совершилъ Преосвященнѣйшій Анатолій.

*Августа 18-го.* Недѣля 11-я по Пятидесятницѣ.

Въ каѳедральномъ соборѣ Божественную Литургію совершилъ Преосвященнѣйшій Михаилъ.

*Августа 21-го. Среда.* Чтеніе Акаѳиста Св. Гурію въ каѳедральномъ соборѣ совершилъ Преосвященнѣйшій Анатолій.

*Августа 22-го.* Торжество въ честь иконы Божія Матери «Грузинскія».

Въ Раиѳской пустынѣ Всенощное бдѣніе, Божественную Литургію и послѣ оной молебенъ совершилъ Преосвященнѣйшій Михаилъ.

*Августа 25-го.* Недѣля 12-я по Пятидесятницѣ.

Въ каѳедральномъ соборѣ Божественную Литургію совершилъ Преосвященнѣйшій Михаилъ.

*Августа 29-го.* Усѣкновеніе главы Пророка, Предтечи и Крестителя Господня Іоанна. Праздникъ Трезвости.

Въ Іоанно-Предтеченскомъ монастырѣ Божественную Литургію и послѣ оной молебенъ совершилъ Высокопреосвященнѣйшій Архіепископъ Іаковъ.

Въ каѳедральномъ соборѣ Всенощное бдѣніе, Божественную Литургію и послѣ оной молебенъ совершилъ Преосвященнѣйшій Анатолій.

Къ 11 ч. дня въ соборъ прибылъ крестный ходъ изъ храмовъ: Всемилостиваго Спаса, что въ Подлужной слободѣ при домѣ Общества Трезвости и Смоленско-Димитріевскаго въ Ягодной слободѣ. Послѣ Литургіи соединенный крестный ходъ изъ каѳедральнаго собора во главѣ съ Преосвященнѣйшимъ Анатоліемъ направился на Ивановскую площадь, куда вышелъ крестный ходъ и изъ Ивановскаго монастыря. Здѣсь Высокопреосвященнѣйшій Архіепископъ Іаковъ въ сослуженіи Преосвященнѣйшаго Анатолія и градскаго духовенства совершилъ молебствіе объ исцѣленіи страждущихъ пьянственнымъ недугомъ.

Среди народа во множествѣ раздавались отъ Казанскаго Общества Трезвости брошюры и листки противъ пьянства.

*Августа 30-го.* Св. Благовѣрнаго Князя Александра Невскаго.

Въ каѳедральномъ соборѣ Божественную Литургію совершилъ Преосвященнѣйшій Анатолій.

# Поученія прот. Н. Воронцова, свящ. Н. Троицкаго и статья проф.-свящ. Ѳ. Успенскаго въ 1600-лѣтнюю годовщину изданія Миланскаго эдикта (14-го сентября 1913 г.) въ переводѣ на татарскій языкъ.

**Ходайнын тере итеӯче, Кадерле Качын торгозган кӧннӧ, (Константинъ падша) христіаннарны жаклаб, Миланъ каласында указъ чыгарганга 1600 жыл тулганны искя алыб бяйрям иткяндя äйтясе угет.**

*Атанын, Улнын, Святый Тыннын исеменя!*

„Эй жаным, Ходайнын Кадерле Качын данна! „Эй жаным, Ходайнын Кадерле Качын торгозоуны олола!“

Ходайнын тере итеӯче, Кадерле Качын торгозоуны искя алыб итя торган бяйрям житте. Бу оло, изге кӧннӧ жыл-сайын, Арыу Жыйын, христіаннарнын жиӈеӯ билгесе, Кадерле Кач карышысында тезлянеб теляк, итеб, Христоснын ӧч жӧз жыллаб жирдя кюмелеб жаткан тере итеӯче, Кадерле Качынын табылыуын да, аннары анын Персія жиреннян кайтарылыуын да искя алыб бяйрям итядер. Äммя быйыл Арыу Жыйын башлыклары христіаннарны Кадерле Качнын боронго заманда иӈ элеке кюренеӯен искя алырга ӧндӧйляр. Бу эш кеше кулы белян кылынмаган, äммя Алла кыуаты белян кылынган, ул жазыклы жирдя булмаган, äммя жугары ауа да, арыу кюктя булган. Безнен багыттан 16 гумер элек изге тормошло Константинъ падша кюктя кодрят белян жондозлардан койолоб торган Кач сюрятен кюргян, шуннан суӈ ул Христосъ дененен жиӈеӯлек биреӯче кыуатын бӧтӧн калык алдында äйтеб кюрсятясе булган. Бӧгӧн бяйрям итеӯебезнен сябябен жакшырак аӈнаб, кюӈелебезне кютярелдерер ӧчӧн, кыскарак кна булса да бу ис китярлек эшне исебезгя тӧшӧрӧйӧк äле.

Христосный жиргя килеўеня ул чакта инде өч жөз жыл ўткян икян. Римъ падшалыгыный кюб жирендя Христосный Евангеліесе сөйлянелгян икян; алай булса да Христосъ денен тотоучылар өчөн ул жыллар бик ауыр булганнар, аларны туктаусыз бик каты азаблаганнар. Ўляр халгя житкян кеше шикелле халсезлянгян жалган деннеляр бар көчляре белян Христосный көннян көн арта киля торган дененя карышы торганнар, Христосъ денен тоткан өчөн кысыулык, азаблаулык онгай арткан, кюб мең христіаннар шул чакта ден өчөн азабланыуныйн вѣнецын оло (сауабын) алганнар. Дюртенче гумернен башында оло Римъ падшалыгын дюрт-биш падша биляб торганнар, шулар арасыннан падшалыкный кояш байышы жагын биляб тороучы бер Константинъ падша гна христіаннарны кысарга тырышмаган. Аны Христосъ денен тотоучы анасы, изге Елена асраб ўстергянгя кюря, ул жомошак кюңелле, сабыр кеше булган: ўзе ул чакта Христосъ денен тотмаса да, падшалыкны акыллы тотоуы белян бютян падшалардан бик кюб айырылган, аный кул астында тороучылар барысыда кинянеб, тыныч-имен торганнар. Ул христіаннарны тырышыучан, гадел кешеляргя санаган, алай булса да элекедян тота килгян жалган деденнян бөтөнняй айырылырга ул чакта уйы житмягян. Тик аный өстөндя Христосъ Качыный кодрятле кыуаты кюренгяч кня, ул шиклянмейче, Христосъ деденя керергя уй тота башлаган. Падшалыкный кояш чыгышы жагында, данныклы Римъ каласында, ул чакта падша булыб, малга гна биренгян усал Максентій тора икян. Аный христіаннарны гна төгөл, жалган деннелярне дя каты кысканый эшетеб, жомошак кюңелле Константинъ аңар кул астындагы кешелярен кысыб азаблаудан туктарга ўтенеб жазыу жазган. Бу жазыуга карышы

Максентій ўзенен катылыгын бигеряк тя арттырыб, Константинга карышы сугыш тотарга äзерляня башлаган. Шуннан суҥ Константинъ, Максентій кулы астындагы кешелярнен интегеўеня чыдый алмыйчы, аларны жаман азаблаучынын кулыннан коткарырга уйлаб, бар чиреўе белян ўзе Римъ каласына барасы иткян. Константинга карышы тороучы Максентійнен чиреўе бик кюб булган, ул ўзенен жалган аллалары булышыр диб ышаныб, аларга бик кюб жяннеклярдян дя, кешелярдян дя корман китергян. Арыу кюҥелле Константинъ, Максентійнен шул хатле чиреўе барын белеб, кюҥеле сюрелеб, аны жиҥя алмам диб, курка башлаган. Шул чакта, Римъ каласына жакыннашарак, Константинъ ўзе дя, чиреўляре дя кинят, кюктя жондозлардан койолоб, жалтраб торган кач кюргянняр, Кач äйлянясендя: „шушынын белян жиҥ“ диб жазган жазыу булган. Мыны кюргяч, Константинъ ўзе дя, чиреўляре дя куркыб, шикляneб киткянняр, алар äле жалган деннеляр шикелле, ўзляре дя жалган денне тотоучы булганныктан, Качны курлык азаб белян азаблый торган коралга гна саныйлар икян. Шул тöннöк Константинъ падшага Качка кадакланыб азабланган Алла Христосъ Ўзе кюренеб, аҥар кач сюрятле сугыш äляме äзерляб, бар сугыш коралларына Кач утыртырга кушкан. Иртягесен падша христіаннарнын священникларын чакырткан, алар аҥар Евангеліедяге ден чыннарын, бигеряк Христоснын Кадерле Качынын кыуатын сöйляб аҥнатканнар. Шуннан суҥ Константинъ эч кюҥеленнян Христосъ деневя керергя äзерлянеб житкян; шундук чиреўляре алдыннан алыб барырга Кач сюрятле äлям жасатыб, Римъ каласына жакыннаша башлаган. Максентій бар чиреўлярен жыйыб, öч табкыр Константинъ белян сугышыб караган, алай да

Христосның Кадерле Качының кыуаты öчöсöндя дя Константинга булышыб, дошманнарын жиңдергян. Калдыгында жаман, денсез Максентiй Римъ каласыннан чыгыб барышлый, бар чиреўляре качыб бетеб, бик кюб салдат башлыклары белян Тибръ сыуында батыб ўлгян, äммя Константинъ дошманнарын жиңеб, ололок белян калага кергян, аны бöтöн калык зур сöйöнöч белян карышы алган. Кала уртасында: „Шушы котолоу билгесе белян мин сезнен калагызны алыб, сезне жаман азаблаучының кыйыныннан коткарыб, Римъ каласының бар кешеляреня дя элекеге даннарын кайтардым“ диб жазыб, Кач утыртыб куйган.

Коткарыучы Христосның жиңеўлек биргяненя тау итеўен Константинъ сюзе белян гня кюрсятмягян, äммя эше белян дя кюрсятясе иткян: ул христiаннарның öч жöз жылдан бирле ден öчöн кысанның кюреўлярен туктатасы булган. Римъ каласына кергяненя бер-аз багыт ўткяч, Миланъ каласында сеңнесенен туйын жасаганда, Константинъ бер бик билгеле указъ чыгарган, ул указъ Миланда бирелгян эдиктъ диб атала. Бу эш Христосъ тыуганнан суң 313-нче жылны булган, алай булгач, аңар инде быйыл тöгял гня 1600 жыл ўткян. Бу указъ буйынча, жалган деннеляргя ўз жолаларын кылыб торорга бойоролган, äммя Христосныкыларга Бер гня чын Аллага табынырга роксят бирелгян. Христосъ öчöн тöрлö азабларга тюзгян христiаннарга, чын денгя öйрянер öчöн öч гумердян бирле катакомбы дигян жир астына казыб жасаган урыннарга качыб жыйылыучыларга бу указъ бик кюб жиңеллек биргян, алар деннярен иркенняб тота башлаганнар, падшалыктагы башлыклар да шуннан суң аларны жаклый башлаганнар. Падшаның Миланда чыгарган указы христiаннар öчöн иң элекеге жакшылыгы булган; ул указдан суң Констан-

тинъ христіаннарга тагы да бик кюб изгелекляр кылган: христіаннарны азаблар өчөн циркъ дигян өйлярдя жасый торган уйыннарны бетерткян, усал кешелярне качка кадаклаб ўтереўне туктаткан, атна көннярдя кара эш эшлямейче, хокөм урыннарына жыйылмыйчы, бяйрям итяргя кушкан; кайда гна булса да христіаннар өчөн чиркяўляр торгозорга роксят иткян, аларга падшалыктагы кюб жортларны буш бирергя кушкан; чиркяўдя кызмят итеўчеляргя имана тюлятмей башлаган, аларны кайда гна булса да кадерляб торорга кушкан, аларга ден тотоу турында киңяш итяр өчөн, иркенняб жыйыннар жыйарга роксят биргян; христіаннарнын жарлыларын, мескеннярен, ўгейлярен, тол катыннарын туйдырыуны падша казнасы өстөня алган. Шушы мыннан 1600 жыл элек Миланъ каласында чыгарган билгеле указы белян Константинъ падша Арыу Жыйын өчөн тагы да бик кюб пайдалы эшляр кыларга уй тоткан.

Бу эшляр булганнан суң инде кюб гумерляр ўткян. Константинъ падшаны Арыу Жыйын изгеляргя кушылдырган, Христосъ деняня пайдалы оло эшляре өчөн, аны апостолларга тиң диб атаганнар. Христосъ дене бөтөн дөньягя жяйелеб, мыннан 1600 жыл элек Константинъ падшанын чиреўе алдында жалтраб кюренгян жиңеў билгесе, Христоснын Кадерле Качы, казер дөньянен бар кырыйларын да жактыртыб тора. Алай булгач, инде Христосъ дене биря торган жан сөйөнөчляреня киняеб тороб, Кадерле Арыу Качка эч кюңелдян кюз салыйык, Христосъ деняня бөтөн дөньягя иркенняб жяйелергя сябяб булган Кадерле Качнын мыннан 1600 жыл элек кюктя кюренгянен исебезгя алыйык. Ул чакта Оло Константинъ падшага кодрят белян булышыб, татыулык коралы белян жи-

ӈелеўсез кыуат биргян Ходайга тау итейек. Бөтөн гумерен Христосъ Качын данналдырырга ўткязгян, апостолларга тиӈ Константинъ падшаны да кадерляб исебезгя алыйык. Кадерле Качнын котолдора торган кыуаты без казерге христіаннарны да жактыртыб, ныгайтсын ыйы, безнен жазыкларыбыз буйынча, жя Христосъ деменя дошманнык итеўчеляр кюблектян, Кач кыуаты бездян бизмясен эйе диб, Ходайга инялейек. Ўзебезгя жалан кыла торган Христоснын Кадерле Качынын котолоу биря торган билгесе безгя äр-бер чакта арыу уйлар биреб, безне сöйöндöрöб, кыуандырыб торсон ыйы. Безгя Алла Ўзе биргян тянебез белян дя, жаныбыз белян дя Аны даннаб, сöйöб, чиркяўнен шушы жырыуларын жырлаб айтейек: „Эй жаным, Ходайнын Кадерле Качын данна! „Эй жаным, Ходайнын Кадерле Качын торгозоуны олола.“ Аминь.

**Константинъ Великійнен (христіаннарны жаклаб) Миланъ каласында указъ чыгарганына 1600 жыл тулган конно айтясе ӱгет.**

„Дöньядя кайгырырсыз, алай да нык торогоз: Мин дöньяне жиӈдем“ (Ев. Іоан. XVI, 33).

Быйылгы жылны Христосъ денен дöрöс тотоучылар, аны бютян тöрлö тотоучылар да мыннан 1600 жыл элек Христосъ Жыйынында булган, бöтöн дöнья калыклары истя тотарлык, бик оло эшне искя тöшöрöб бяйрям итяляр. Бу эш: Римъ Падшасы Константинъ Великійнен 313-нче жылны христіаннарга ўз деннярен иркенняб тотарга Миланъ каласында указъ биреўе. Бу бöтöн дöньянен тормошон ўзгярткян эш безнен уйыбызга ўткян гумерлярне, Христосъ денен тотоучыларнын элекеге гумерлярен искя тöшöря. Бу гумерляр

ӱткянгя инде бик кюб багыт, алай булса да кешеляр аны оноторлок тӧгӧл; ул чакта, Христосъ дене жанга гна жяйеля башлаган багытта, христіаннарны бик кысканнар. Кеше Аллага карышылык иткян, дӧнья Христоснын денен кюря алмаган, чиркяӱ жырыуында айткянчя: „Христосъ денен тотоучылар Кач кыуатынын данын бӧтӧн жиргя жяйелдергянняр.“ Алар Кач турысында сӧйлягянняр, ӱзляре дя Кач кютяреб барыучылар булганнар. Кач арткылы куйылган дѐн ӧчӧн алар азабланыб, мянгге тормошно алыр ӧчӧн ӱлгянняр дя. Коткарыучы изгелеге буйынча, арыулыкнын бӧтӧнняй жиӊелгян дошманы, усаллыкка котортоучы, кюремсез шайтан христіаннарга карышы бар кӧчӧ, жанны ӱтеря торган хайлясе белян тотонган. Шайтан котортоуы буйынча, жалган денне тотоучыларнын бар жыйын башлыклары, падшалары, белемне, укымыш кешеляре, кара калык, ӧйрятеӱчеляре, хокӧм итеӱчеляре барысы бер булыб, Христоска кюремсезлек итеб, Анын исемен бӧтӧнняй жукка чыгарырга тырышканнар. Кара калык жарсыб кычкырган: „Христіаннарны арысланнарга ботарлатыб, качка кадаклаб бетерергя киряк“, диб. Белемне кешеляр Христоснын денен жукка ышаныуга санаб, падшалык ӧчӧн бик оло хатяргя куйыб, кадакланган Христоска ышаныучыларны кюря алмаганнар. Жалган деннелярнен сыннарга корман китереӱчеляре христіаннарны, аллаларны белмягяннекляреn, аннары кешелярне сӧймягяннярен кюрсятеб айыблаганнар. Сынга табыныучыларнын белемне кешеляре Христосъ денен тотоучыларны, Кач турысында, тагын ӱлгяннян суӊ буласы мянгге тормош турысында сӧйлягянняре ӧчӧн, кюря алмаганнар. Падшалыкны тотоб тороучы тюряляр Христосъ денен бӧтӧнняй жукка чыгарырга тырышканнар, Аӊар ышаныучыларны азабларга тӧрлӧ

азаб кораллары жасатканнар. Бер Алланы кадерляўчеляргя хокӧм урыннарында ўтерелергя эш кылганнар.

Азабланган христіаннарнын каны жирне кызарткан, тик бу канны алар жылаб, ыӊырашыб, зарланыб тюкмягянняр, äммя бик зур сӧйӧнӧчкя тулыланыб, кадакланган Христоска даннау жырыулары жырлаб агызганнар. Алар азабланганда кюккя караб, интегеб жыламаганнар, äммя жиӊеў жырыулары жырлаганнар. Кеше чыдый алмаслык азабларга тюзеўляре белян алар азаблаучыларнын ўзляренен ислярен китергянняр; шул ден ӧчӧн азабланыучыларнын азаблары арткылы Христосъ дене ўзенен ис китярлек матурлыгын, жиӊелмяслеген, Алладан булган ден икянен кюрсяткян.

Ден ӧчӧн азабланыучыларнын каны арткылы Христосъ Жыйыны Ўзенен азабта тора торган кешелярен тулы сӧйӧўлек белян сӧйгянен айырмачык кюрсяткян; аннары тагы äгяр дя дӧнья ўзенен акылсызлыгын ташлаб, Качка кадакланган Христоснын арыу сӧйӧўлеген белеб, буласы мянгe тормошка ышанса, Ўзенен äртӧрлӧ азабка äзер торганын да кюрсятер эйе. Ӧч жӧз жыл карангылык белян усаллык падшалыгы, жактылык белян арыулык падшалыгы жиӊешкян. Ӧч жӧз жыл кеше ўзенен Булдырыучысына, Коткарыучысына карышылык иткян. Калдыгында, дӧнья кӧчӧ житя алмаганына ачыуы килеб, халдян тайган. Азаб кораллары ўтмяслянгянняр. Падшалыкны тотоб тороучылар ўзляренен жиӊелгянняреп белгянняр. Алла сынга табыныуны жиӊеб, кешелярне коткарган.

313-нче жылнын башында Константинъ Великій ўзенен Кач кыуаты белян каты кюӊелле Максентійне жиӊеўен истя тотар ӧчӧн, ўз кул астындагы калыкларга Миланъ каласында указ биргян; шул указ буйынча христіаннарга ўзляренчя Аллага теляк итяргя

ирек булган, аннары тагы äр-кемгя Христосъ деneня чыгарга да роксят бирелгян. Алланы сöйöўчян падшанын бу указына Христосъ денен тотоучыларнын Жыйыны айтеб житкезя алмаслык сöйöнöч белян сöйöнгян.

Христосъ дене сынга табыныуны бöтöнняй жингянне ўз кюзе белян кюреўче, Кесаріяда епископъ булыб торган Евсевій былай диб айтя: „Казер бöтöн дöньядя тороучы Христосъ денен тотоучыларнын Жыйынына кюктян болотсоз, жакты, ачык кöн жактырылды. Безнен сöйöнöчöбез безнен кылган эшляребезгя караганда артыгырак. Бу хатле оло дяўлятне кюрсятеўче Алланын изгелеген кюреб, безнен исебез китя“, дей. „Жяшляр дя, картлар да, ирляр дя, катын-кызлар да чын кюнгел белян сöйöнöшöб, бу изгелеклярне кюрсятеўче Аллага тау итеб, теляк китеряляр“. дей.

Миланъ каласында биргян указ христіаннарга изгелек китергян бар указларнын башы, шул указ буйынча, Христосъ Жыйынын кысыу тукталган, падшалыкта тороучылар да христіаннарнын арыу кешеляр икянен ангнаганнар. Христосъ денен тотарга ирексезлек итеў тöгöл, аны Аллага жараулы бер гня чын ден диб белгянняр. Константинъ Великій указында Христосъ дене турысында былай жазган: „законга тейешле, бöтöн дöньягя куйылган, Алланы кадерлей торган инг арыу ден“, диб. Падшалыкнын кыуаты Кач кыуатына багынган, „шушынын белян падшалык ит, мынын белян жинг“ дигян сюзляр буйынча, шуннан ары Кач сюряте анын данынын, кыуатлылыгынын билгесе булган. Элгяре Христосъ дененя карышы тороучы башлыклар, инде аны жаклаб, саклаб тороучылар булганнар; сыннарга табына торган падшалык Христосъ денен тотоучылар падшалыгына алмашкан. Падшалык сыннарга табыныунын электян бирле киля торган жо-

лаларыннан тангган, Христосъ дененен чын маганясен ангнаб, ӓдям ней ӧчӧн булдырылганны, аннары падшалыкнын алга таба барыуынын, арыу кӧнняр кюреӳенен нык нигезе Христосъ дене икянне белгян.

Христосъ Жыйынына ирек биреӳе белян, падшалык ӳзенен Арыу Жыйыннан булышыулык киряксенгянен, христіаннар кадерляб ышана торган Алланын изгелеген табарга тырышканын кюрсяткян. Арыу Жыйын бик куркынгыч кысанкы багытта да торган, мыннан ары да Алладан бирелгянчя, бозолмойчы, бӧтӧн кӧйӧ сакланыр, ӓммя Христоснын чын дӧрӧс дененнян башка падшалык рятсезлянеб, таралыб бетяргя тейешле була. Константинъ Великій бар указларында да, Христосъ денен жаклауы белян ӳзенен падшалыкка арыулык кылганын, калыкларга пайда китерергя алар ӧчӧн бик сагышланганын айырмачык айтеб кюрсяткян.

Арыу Жыйын падшалыкны кысанныk кюрсятеӳче усал падшалар кулыннан коткарган.

Христосъ денен падшалыкта тотарга ирек итеӳче императоръ Константинъ падшалыкны ӳзе гня башкарыб тороучы, жингелмяслек падша булган. Арыу Жыйын арткылы котолган падшалык, ангар ӳзе дя чамасыз кюб пайда китергян: законнар биреб, христіаннарга ӳзляре телягянчя торорга ирек иткян. Миланъ каласында биргян указы белян, аннары шул указны ангнатыб чыгарган бютян указлары белян, Константинъ Великій Арыу Жыйынга ӳзенен тормошон Алладан бирелгян ӳз законнары белян рятляргя ирек иткян.

Шул батыттан ары христіаннарнын кюнгелляре кютярелеб, кӧннян кӧн Арыу Жыйынның жамагатын арттырганнар. Ул чакта Арыу Жыйынны падша законы кысыу тӧгӧл, ӳзе аны жаклаб, саклаб торган, шуннынктан Арыу Жыйын ӳзенен жакщы тормошон тӧрлӧ жак-

тан ўстергян, ўзенен бар жяшерен торган кыуатын, байлыгын кюрсяткян. Арыу Жыйын келяў итеў рятен тӧзӧб, келяў ӧйлярен жаӊартыб житкезгян, келяў жолаларын Аллага жараулы итеб матурлаган. Алла престолы карышысында кызмят итеўче архіерейлярнен келяў итеўляре, священниклярнен келяў иткяндя кыла торган арыу эшляре тулы, жакшы булган. Келяў ӧйӧндя кызмят итеўче архіерейляр, священникляр, бар калыкка ўгет айтеб, келяўгя жыйылган кешелярнен кюӊеллярен кютяргянняр. Келяў ӧйлярен жаӊартыб арыуландырыу бяйряменя Христосъ денен тотоучы тӧрлӧ калыклар бергя жыйылышканнар, шулай итеб, алар бер берсе белян жакыннашыб, Христосъ Тяненен саннары бергя кущылыб, бер кеше кюк булганнар. Аларнын кюӊелляре, ышаныулары бер тӧрлӧ булыб, барысынын ауызыннан Аллага бер тӧрлӧ даннау жырыулары кютярелгян. Христіаннар тормошона рят кертелгян: кечеляр ололарга баш салыб тороу турысында бойороклар куйылган, Церковьне тотоб тороу турысында бик айбят законнар чыгарылган. Арыу Жыйын саклаб тора торган иӊ оло чыннар, алтын кюк айбят гумердя торган изге аталар белян, Арыу Жыйынны ӧйрятеўчеляр жазган княгяляр дя тӧрлӧ жактан бик тулы аӊнатыла башлаган, аннары ден чыннарын Оло Жыйыннарда изге аталар айырмачык аӊнарлык бергя жыйыб жазганнар, аларны бар кешелярнен дя уйы сыйыштырырлык булган.

Чыннықны белгян ӓдям, Алла булдырган нястяларне аӊнаб белясе килгяннектян, Христосъ денендя тӧрлӧ белемнеклярга ӧйрянеў чыккан. Дӧньядяге нястяларне белеб, аларны жакшыландырасы килгяннектян, христіаннарнын тормошо да элекегя караганда бик арыуга айлянгян. Христосъ дене барысына да кыуат биреб,

ӳзенен жяшерен сауытындагы жактысын дӧньягя чыгарыб, кешелярнен тормошон бар жактан да жактырткан, ул жакты айырым жамагат арасында да, школда да, жыйын калык арасында да жактырган. Шулай итеб, дӧнья Христосъ кушканны кыла башлаган, Христосъ аны бӧтӧнняй ӳзгяртkян. Жамагатнын ӧйӧ келяӳ ӧйӧ-чиркяӳ кюк булыб, ӳзенен эчендя Христоснын Арыу Жыйынынын жактырткычларын, Анын ис китярлек оло эшляр кюрсятеӳче ден ӧчӧн азабланыучыларын, тагы денне таныклаб кюрсятеӳче изгелярен асраб ӳстергян. Школ арыу тормошка ӧйрятеб, чынкык турысында, жан турысында белемнеккя ӧйряня торган урын булган. Кешеляргя Христосъ дененен сӧйӧӳлеге сеңя башлаган. Ӑӳаледян бирле тора торган коллок,—сыннарга табыныу,—жукка чыккан, бар калыклар да Алла оланнарынын данынын иркеннегеня чакырылганнар. Хокӧм урыннарында эшлярне, Христосъ эконынын изгелеге, дӧрӧслӧгӧ кушканча, тикшеря башлаганнар. Епископларга айыбланыучыларны жакларга ирек бирелгян. Христiаннарны падшалыкнын иң арыу кешеляреня санаб, падшалыктагы, калык арасындагы оло урыннарга баш итеб куя башлаганннар; алар падшалыкны тотоу турысындагы эшлярне кылганда, ӳз жакларына бютян тюрялярне дя ӑӳерелдергянняр. Бер Аллага бер тӧрлӧ ышаныу булганныктан, падшалыкта тормош ряткя килгян. Падшалык Христосъ денен аңный башлаб, ирек кюңелдян Христосъ Жыйынынын бойороклары кушканны кылыб тора башлаган, ӳзенен тӧрлӧ ӑмялляре белян Аллага жараулы эшне кылыб, жир ӧстӧндя Алла падшалыгын торгозорга булышкан. Шулай итеб, ике тӧрлӧ тормош татыуланыб, бергя кушылганнар: Алланыкы белян кесарьнеке, жирнеке белян кюкнеке бер тӧрлӧ булганнар. Падшалык Церковь пай-

дасына тырышкан, бигеряк жан турысында сагышланган. Церковь падшалыкнын кюнгелен кютяреб, ангар Аллага кирякле эшлярне кылдырган.

Падшалык белян бер булыб, Церковь ӱзенен кыласы эшлярен чит жирляргя дя жяйелдергян. Алла княгяляре тӧрлӧ теллярге: персія, индія, египетъ, готѳъ телляреня кючерелгян, шулай итеб, Арыу Жыйын бӧтӧн дӧньягя жяйелгян.

Константинъ Великій бик оло эш кылган. Айырым тора торган кешелярнен, жыйыннарнын, калыкларнын, падшалыкларнын, дӧньядяге бар кешелярнен рятле тороуынын маганясе бӧтӧн жиргя куйылган Арыу Жыйынннын чыннарын белеб, саклаб, аларны кылыб тороу икянне ул ангнаган, шунгар кюря ул буласы гумерлярдя дя ӱзе кылган эшне кыларга кушкан. Шушы бик оло эше ӧчӧн Константинъ падшаны Арыу Жыйын Апостолларга тинг диб атаган, ӓммя исторіяда ул Великій диб айтеля.

Миланъ каласында бирелгян указдан сунг ӱткян 16 гумердян дӧньянен Христосъ кыуаты белян гня торганы кюренеб тора; Христостан башка калыклар да ӱлеб бетяляр, падшалыклар да жукка чыгалар. Бар калыклар да алдагы багытта арыу кӧнняр кюрербез диб, ӧмӧт тотоб торалар, ӓммя Христостан башка ул турда уйларга да туры килмей. Ӱз тормошонда Христосын дӧрӧслӧгӧн белеб, аны жиреня китереб кылыб тороучы калык кна ӱзен бетеӱдян саклый.—Исторія уроғын онотмойок.

Ӱзебезнен кюнгелебездя гумер буйынчы Христоснын Качын жӧртӧйӧк. Калыкларнын тынычлаб, бербереен сӧйӧб, арыу тороулары Кач кыуатыннан гна буладыр. Аминь.

**Христосъ денен тотоучыларны кысыб азаблауның тукталыуына быйыл 1600 жыл тулганны искя алыу.**

Әүәле іудейляр белян жалган деннеляр Христосъ денен тотоучыларны бик каты кысканнар. Бу эш өч гумердян артыкка барган. Падшалар да, князляр дя ул багытта жалган денне тотоучылар булганнар, шуңар кюря алар Христосъ денен жалган деннелярдян жаклау урнына үзляре христіаннарны бик каты азаблаб кысканнар. Былай азаблауны дөрөс денне тотоучы Константинъ Великій туктаткан. Ул бик зур, бик данныклы Римъ жиреня падша булыб 306—337 жылга чаклы торган. Шушы Римъ падшалыгында христіаннарны кысыудан, бютян калыклар да Римъ падшасыннан шикләнеб, христіаннарны кысыудан туктаганнар. Шулай казер дя Төрөк жирендя Мохаммят денен тотоучылар, аннары Кытай жирендя Буддага табыныучылар, Урыс падшасыннан куркыб, аның христіаннарны жакласын белеб, Христосъ денендягелярне бигюк кыйырсытмыйлар. Бу Константинъ падшага христіаннарны кысанныктан коткарырга уй ничек төштө икян? Ул уйны аңар Алла Үзе биргян. Ходай Іисусъ Христосъ Үзенен Арыу Жыйынын кюренмейче Үзе башкарыб тора. Шулай Алла дөнья өчөн сагышланыуы буйынча, чын денне тотоучыларны іулейляр белян жалган денneляр кысыуы тукталыр багыт житкяч, Константинъ падшаның кюңелен жомошатыб, аны Үзеня ауыштырган. Бу турда булган эшлярне дөрөсляб жазыучылар былай айтя: 303-нче жылда Діоклетіанъ падша Христосъ денен тотоучыларны бик каты азаблый башлаган. Аннан суң да христіаннарга тыныч булмаган. Римъ падшалары үз аралый бер дя татыу булмаганнар. Шул падшалар арасында берсе Константинъ Великій булган. Ул Римъ падшалары арасында иң кечесе булган. Ул падшалыкка

атасы Констанцій Хлоръ артыннан утырган. Діоклетіанъ кул астында тороб, Констанцій Хлоръ Галлія белян Британія дигян жакны тотоб торган. Ӱлгян чагында, ул Римъ падшалыгынын бӧтӧн кояш байышы жагына падша булыб ӱлгян. Христосъ дененен жактысы аҥар бик жакыннашкан, алай да ул жалган дендя кӧйӧ ӱлгян. Бар Римъ падшалары арасында бер ул гна христіаннарга жагымны булган. Ӱзенен улын да ул Христосъ денен тотоучыларны сӧйяргя ӧйрятеб ӱстергян. Тик анын улы да атасы кюк жалган дендя озак торган. Анын анасы изге Елена Христосъ денен тотоучы булган, улын да чын денгя ӧйӧряткян; тик Константинъ жяшлеген сугыш эшлярендя, тӧрлӧ уйыннарда ӱткяргян. Ул кояшка табыныучы булган. Бютян жалган деннеляр кюк, ул да кояшны иҥ оло аллага санаган. Аннан былай тагы Константинъ Великійне, сабыр атасы белян изге тормошло анасыннан биздерер ӧчӧн, Діоклетіанъ жортона алганнар. Констанцій Хлоръ ӱлгяч, Константинъ Великій атасы кюк Галлія белян Британіяга падша булган. Тик ул падша булыуы белян аҥар биш падша карышы тороб, аны падшалыгыннан тӧшӧрӧб, анын бар жирлярен алырга бик тырышканнар. Константинъ Великій алар белян бик озак тартышкан, калдыгында ул падшалыгында ныгайган. Анын бер дошманы, бик оло, усал эшляре ӧчӧн, аҥар Алла жибяргян хатяр чирдян ӱлгян. Икенчесе ӱзен ӱзе ӱтергян. Ӧчӧнчӧсе сугышта ӱлгян. Дюртенчесе Константинъ Великійгя карендяш булыб, анын белян татыуланышкан. Константинъ Великійнен бишенче дошманы анын белян татыуланасы килмягян. Бу Италія белян Африка падшасы Максентій булган. Анын кул астында Римъ каласы булганга кюря, ул Константинъ Великійгя бик хатяр дошман булган. Максентій сын-

нарга табыныучы булган. Ӳз кул астындагыларга ул бик каты булган, бигеряк ул христіаннарны жакшы тормошлары ӧчӧн кюря алмаган. Тагы да ул ӳзе бик азгын кеше, бушка ышаныучы булган. Римъ калкы анын акылсызлыгыннан, катылыгыннан бик кюб азаб кюргян. Ӓммя Британія белян Галлія падшасы Константинъ Великій бик сабырлык белян, акыл белян падшалык иткяне аларга билгеле булган. Шуңгар кюря алар Константинъ Великійгя жяшертен кат жибяргяння р, чиреӳ жыйыб килеб, безне усал падшадан коткарсана диб. Константинъ Великій ӳзе башлаб, Максентійгя карышы сугышка чыгарга озак уйлаб торган. Ӓммя Максентій акылсызланыб, Константинъ Великійгя ӳзе башлаб карышы эшляр кора башлаган. Ул Константинъ Великійнен жире белян жяняшя калаларда анын сыннарын ыуатыб ташларга кушкан. Мыннан ары Константинъ Великій бер кауым салдатларын жыйган, ней бары 25 меӊ кеше. Шуннан артык салдат жыйа алмаган. Ул багытта Галлія белян Британіяга Германія жирендяге жаман калыктан жалан куркыч булган. Бу дошманнардан ӳз жирен саклар ӧчӧн, Константинъ падша Рейнъ дигян сыу буйындагы калаларда, Британіядагы крѣпостларда кюб чиреӳ калдырган. Шулай итеб Константинъ Великій аз гна салдатлар белян Римъ каласына барыб, денсез, жаман Максентійне тыясы булган. Ул сугышка барырга чыккач, бер табкыр жулда бик зур уйга тӧшкян. Аӊар: Максентій бик кюб чиреӳ жыйыб, 170 меӊ жяйяӳле, 18 меӊ атлы салдатлар белян, сине жиӊяргя киля диб житкезгянняр. Жалган денне тотоучыларнын корман башлыклары, кюрязяляре Максентійгя: син жиӊярсеӊ, Римъ аллалары сиӊа булыша диб алдан айтеб торганнар.

Константиннын салдат башлыклары белян салдатлары бу хабярлярне эшеткяч, кюнгелляре сюрелеб, каушаб киткянняр. Алар: Константинны жингяч, безне тотконга алыб, качка кадакларлар, жя коллокка сатарлар диб уйлаганнар. Константинъ Великій бу турларда уйлаб торган чакта, анын исеня ӑўалеге падшалар тӧшкян. Бу падшалар хатяр килгяндя ӧмӧтлярен жалган аллаларга тотканнар, тик жалган аллалар аларга бер тӧрлӧ дя булыша алмаганнар. Ӑммя анын атасы Констанцій Хлоръ жалан бер Аллага гна ӧмӧтлянгян, анын эшляре гел унган. Быларны уйлаб, Константинъ Великій теляк итя башлаган. Ул кояшны аллага санаганга кюря, кюзлярен кояшка кютяреб караб торган. Бу эш кичкя таба булган, кояш жактысы сюрелгян икян. Кинят Константинга кояш астында Кач кюренгян, ул Кач ӧстӧндя: „шушынын белян жин“ диб жазылган жазыуы булган. Падшанын чатыры ӑйлянясендя торган чиреўляре дя бу кюктяге билгене кюргянняр. Мыны кюреб, барысынын котлары чыккан. Алар: бу кюктя кюренгян Кач безгя жингеўлек бирмяс, ӑммя зур кайгы гна китерер диб уйлаганнар. Тик Константинъ гна кюнгелендя бютян тӧрлӧ уйлаган. Ул ўзе жалган денне тотоучы булса да, христіаннарнын Качны кадерляб, аңар табынганнарын белгян. Шунда ул ўз чатырында тезлянеб теляк итя башлаган. Тик ул инде кояшка инялмягян, ӑммя кюктя кояшны жактыртыучы, кешелярнен кюнгелен жакшыга ауыштырыучы, Ходай Іисусъ Христоска инялгян. Падша ўз чатырында бик озак, чын кюнгелдян теляк иткян. Кояш байыган. Тӧнгӧ карангы бар чиреўляр жыйылыб торган жирне каблаб алган. Падша теляк итеб арыгач, жокога киткян. Алайда анын жокосо тыныч булмаган: аңар тӧрлӧ тӧшляр кергян. Шул тӧшляр арасында берсе падшага бигеряк

ис китярлек тейгян. Ангар Іисусъ Христосъ Ўзе бик кюб пяриштяляр белян кюренгян. Ул ангар őстőня кач тőшőргян сугыш äляме жасатырга кушкан. Константинъ Великій мыны тизюк кылган. Икенче кőннő иртюк ул осталар чакырыб, аларга ўзе кюктя кюргян билгегя ошаулы качлы äлям жасарга кушкан. Бу äлямне чиреўляр алдыннан алыб барырга кушыб, бар чиреўляре белян кузгалган. Падша да, анын санатлары да бу эшлярдян сунг бик жőряклянеб, дошманнардан бер дя курыкмас булганнар. Дошман белян тизеряк очорашыб, аны жингеб, жыуашландырыб, анын кюрязялярен оятка калдырмакчы булганнар. Дошманнар белян őч табкыр очорашыб сугышканнар. Максентійнен чиреўе бик кюб булса да, Качлы äлям тоткан чиреўлярне очораткач, барысы да качыб беткянняр. Калдыкта Константинъ Великій Римъ каласынын жанынук килеб житкян. Максентійгя бу калада биклянеб, дошманнарга карышы торорга бик жай булган. Жалган деннелярнен кюрязяляре бик куркыныч кюрязялек итеб, Максентійне жингярсен диб ышандырыб торганнар. Аларга ышаныб, Максентій каладан чыгыб, Тигръ сыуы арткылы корган Мильвійскій дигян кюпердян чиреўлярен алыб чыгыб, Константинъ Великій белян сугыша башлаган. Бу сугыш озак булмаган. Арада бик батыр 50 салдат алдыннан тотоб килгян Кач äляме Максентій чиреўляреня кот чыгаргыч куркыныч тőшőргян. Салдат башлыкларынын бик кюбесе ўлгян. Максентій ўзе дя куркыб, утырыб килгян атын кире борган. Мильвійскій кюпергя менгяч, ул кюпер калтрый башлаган. Максентій сыуга тőшőб, Тибръ сыуынын тулкыннарында баткан. Константинъ Великійнен чиреўляре Кач äлямен тотоб, шул кюпердян бер зыянсыз ўтеб, Римъ каласын чырмаб алганнар, шуннан сунг тизюк Константинъ Великій

ӱзе дя бик зурлык белян калага кергян. Римъ каласы бар башлыклары белян бик сӧйӧнӧб, аны карышы алганнар. Тик бу кыуаныб кадерляӱне падша ӱзеня алмаган, ул Ходай Іисусъ Христоска тау иткян. Кач ӓлямен бар калык кюрерлек урынга куйдырган. Мыннан суӊ Константинъ ӱзенен христіаннар ышана торган Аллага ышанганын чын кюӊеленнян бар калык алдында эштеттереб ӓйтеб биргян. Максентійне жиӊгяч, Константинъ Великій Римъ падшалыгынын кояш байышы жагына падша булган. Ул ике айга жакын Римъ каласындагы эшлярне тикшереб рятлягян. Ул Максентійнен дӧрӧс тӧгӧл, бар каты, ауыр кушыуларын ӱнгяртеб, христіаннарга келяӱ итяргя каладагы базилик дейгян жортларны биргян. Чиркяӱляргя кюб акча салган, изге азабланыучыларнын тяннярен кадерлягян.

313 жылнын башында Константинъ Великій Римъ каласыннан Миланъ дигян калага киткян. Мында ул императоръ Ликиній белян очорашкан. Ликиній ул багытта Римъ падшалыгынын кояш чыгышы жагында падша булыб тора икян. Алар ӱзляренен Бер гня Чын Алланы ололаб кадерлягянннярен ней белян кюрсятергя киӊяш корганнар. Аннары алар бӧтӧн падшалыкта бар калык ӧчӧн дя закон чыгарасы булганнар: Христосъ деменя бер тӧрлӧ дя, бер тӧштя дя кысыулык булмасын диб. Христіаннарнын элеке ирексезляб алган малларын аларга кире бирергя кушылган. Жалган денне ташлаб, чын денгя керясе килгян кешегя тӧрлӧчя булышырга тейеш булган. Бу законны 313 жылда жазыб, Константинъ белян Ликиній Миланъ каласында кулларын куйганнар.

Шуӊар кюря бу закон Миланскій эдиктъ диб аталган, аннары тагы аны Константинъ Великій манифесы диб атыйлар. Ликинійнен исемен суӊгыннан бу законга кушмый башлаганнар. Ликиній бер ка-

уымнан суң бу законга ўзе карышы кылган, шунын öчöн Константинъ Великій аны падшалыгыннаб тöшöрöб ўтерткян. Миланда бирелгян указда былай жазылган: Миланга барыб житкяч, без падшалыгыбызда калык пайдасына кирякле эшляр турысында бик аң салыб уйлаб, падшалыгыбызда Алладан куркыб, Аны кадерляб тороулык ныгайсын диб, былай куйдык: беряўгя дя Христосъ деняня керергя тукталыу булмасын, элекеге указларда христіаннары кысыб читляргя кушыулар бетсен. Христіаннарнын ирексезляб, жя сатыб алынган келяў урыннары, жортлары аларга кире, акчасыз бирелсен. Тагы жирлярне сатыб, жя бюляк итеб алган кеше, алар öчöн акча аласы кился, безнен башлыкларга билгеле итсен, без анын сорауын буш итмябез, диб. Мына Миланскій указда иң элеке шушы тур жазылган. Шушы христіаннарны жаклый торган закон чыкканга инде 1600 жыл узган. Элеке бирелгян ауыр законнарны Константинъ Великій ўзе ўңгярткян. Шуңар кюря бу 1913 жылда Арыу Жыйын Христосъ денен тотоучыларнын кысанныктан, азабтан котолганнарына сöйöнöб бяйрям итя. Кач кыуаты белян денебез ныгайганга Арыу Жыйын безне Аллага тау итяргя öндöй.

Святѣйшій Синодъ бойорган буйынча, бу бяйрям Кач кютярелгян кöннö 14 сентябердя ителергя тейеш. Бу кöннö жырлана торган чиркяў жырыуларында айтелгянчя, без бу кöннö Христоснын Кадерле Качынын кыуатыннан булган бик кюб кодрятле эшлярне искя алыб бяйрям итябез. Ул эшлярнен иң элекегесе бу: Арыу Жыйыннын, Христоснын Кадерле Качынын кыуаты белян, христіаннарны кысыб азаблаучыларны жиңеўе. Бу эш Константинъ Великій арткылы кылынган. Ул Кач сюрятле äлям белян христіаннарны бик каты кысыучы Максентійне жиңгян. Шулай казер дя сугыш багытында, салдатлар Константинъ Великій багытын-

